КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 28 август г.Казань № 714

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2018 ел, 31 май, 412 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2018 ел, 31 май, 412 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 31 октябрь, 965 нче; 2018 ел, 29 декабрь, 1262 нче; 2019 ел, 11 июль, 565 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәдә:

II бүлекнең 2 пунктындагы таблицаның «Мәдәният, сәнгать һәм кинематография өлкәсендә әйдәп баручы звено хезмәткәрләре вазыйфалары» һөнәри квалификация төркеме» бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| «Мәдәният, сәнгать һәм кинематография өлкәсендә әйдәп баручы звено хезмәткәрләре вазыйфалары» һөнәри квалификация төркеме | | |
|---|---|---|
| Китапханәче | 10 500 | 13 000»; |
| Тавыш операторы | | |
| Әйдәп баручы китапханәче | | |

| | | |
|---|---|---|
| Рәссам-декоратор | | |
| Баш китапханәче | | |

VI бүлекнең 13 таблицасындагы 2 пунктка түбәндәге эчтәлекле 2.3 – 2.5 пунктчалар өстәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «2.3. | Әйдәп баручы китапханәче | 42 |
| 2.4. | Рәссам-декоратор | 45 |
| 2.5. | Баш китапханәче | 45»; |

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт һөнәри белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәдә:

II бүлекнең 1 пунктындагы таблицада:

«Педагогик хезмәткәрләр вазыйфаларының һөнәри-квалификация төркеме» бүлегенең «Дүртенче квалификация дәрәҗәсе» юлына түбәндәге эчтәлекле юл асты өстәргә:

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | «Педагог-китапханәче* | - | - | 14 236»; |

түбәндәге эчтәлекле асъюл өстәргә:

«* Төп гомуми белем бирү программаларын һәм урта гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы дәүләт һөнәри белем бирү оешмалары өчен.»;

әлеге Нигезләмәгә 3 нче кушымтаның 1 таблицасына түбәндәге эчтәлекле 3.23 пункт өстәргә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| «3.23. | Педагог-китапханәче | дүртенче | 60»; |

әлеге карар белән расланган Югары белем бирүнең мәгариф программаларын – бакалавриат программаларын, специалитет программаларын, магистратура программаларын тормышка ашыру буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган югары белем бирүче дәүләт мәгариф оешмалары һәм Татарстан Республикасының өстәмә һөнәри белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәнең IV бүлегендәге 4.1 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

$$«O_d = O_b \times S \times K + P + N,».$$

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин